Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советының егерме өченче утырышы

Колай авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

29 май, 2020 ел № 69

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм төгәлләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге Советы карарына кушымта 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы Колай бермандатлы сайлау округына түбәндәге йортларны кертеп төгәлләштерергә:

а) Колай № 1 бермандатлы сайлау округына Яшел урамындагы 1нче йорт; Чкалов урамындагы 15А, 20А, 21, 22 нче йортлар; Совет урамындагы 18 нче йорт.

б) Колай № 2 бермандатлы сайлау округына Профсоюз урамы буенча 16 нчы йорт.

в) Колай № 5 бермандатлы сайлау округына Яшьләр урамы буенча 3А, 16Б номерлы йортлар.

г) Колай № 6 бермандатлы сайлау округына Яшьләр урамы буенча 72, 94, 103, 106 номерлы йортлар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская